**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 сентябрь № 708

г. Казань

Нурлат муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Кондурчанефть» ачык акционерлар җәмгыятенең Нурлат муниципаль районында урнашкан, 10,44 гектар гомуми мәйданлы, «Кондурчанефть» ачык акционерлар җәмгыятенең милкендә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән кадастр паспортларында күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:32:030403:1418 | 0,8756 |
| 16:32:030403:1419 | 0,1871 |
| 16:32:030403:1420 | 0,9765 |
| 16:32:030403:1421 | 0,8774 |
| 16:32:030403:1422 | 0,154 |
| 16:32:030403:1423 | 0,6655 |
| 16:32:030403:1424 | 0,011 |
| 16:32:030403:1425 | 2,0 |
| 16:32:030403:1426 | 1,9767 |
| 16:32:030403:1427 | 0,1249 |
| 16:32:030403:1428 | 0,1839 |
| 16:32:030403:1429 | 0,4705 |
| 16:32:030403:1430 | 1,24 |
| 16:32:030403:1431 | 0,6969 |
| Барысы | 10,44. |

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\708.docx